**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Сухояшского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**
ул.Школьная, д. 4-2, село Большой Сухояш, Азнакаевского муниципального района, 423325
Тел. (факс) 34-6-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**
Мәктәп урамы, 4-2, Зур Сукаеш авылы, Азнакай муниципаль районы, 423325,Тел. (факс) 34-6-16

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» окябрь 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең Зур Сукаеш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020 елның 29 октябрендә 12 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены билгеләргә.

2.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының уздыру вакыты – 29 октябрь 2020 ел 12.00 сәг.тән 13.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының уздыру урыны – Зур Сукаеш авылы, Совет ур. , 34 йорт, Зур Сукаеш авыл мәдәният йорты залы;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 25 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу

хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Зур Сукаеш авылы, Мәктәп урамы, 4-2 йорт

- сайлау хокукына ия булган Зур Сукаеш торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
- Зур Сукаеш торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә һәм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәннәрдән 150 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Зур Сукаеш авыл җирлегендә урамнарны яктырту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү);
- Тракторчыга карны механикалаштырылган җыю хезмәте өчен түләү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре);
- Зур Сукаеш авылы территорияләрен төзекләндерү (территорияне механикалаштырылган чабу хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу).
- Зур Сукаеш авылы зиратын киртәләп алу өчен материаллар сатып алынды, зират коймаларын әзерләү һәм урнаштыру, лак-бояу материалы алу, килешү буенча эшләр өчен түләү.

« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Зур Сукаеш авылы, Совет ур., 30 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: З.Җ. Закирова